ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03.2021 № 173

Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының яңа редакциясен раслау турындагы 2020 елның 13 ноябрендәге 944 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының яңа редакциясен раслау турында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13 ноябрендәге 944 номерлы карары һәм «Салым түләүчеләргә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау) турында мәгълүмат бирү эшен оештыру турында» 2021 елның 27 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 13 ноябрендәге 944 номерлы карары белән расланган гражданнар милкенә муниципаль торак фондының торак урыннарын тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия ФСХнә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр»;

- 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу»;

- 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«9) законнар бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч барлыгы (булмау) турында белешмәләр».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин